РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТА РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** Буа шәһәре **КАРАР**

05.05.2026 №5-11

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы милкенә караган, торышы канәгатьләнерлек булмаган Россия Федерациясе халыкларының файдаланылмый торган мәдәни мирас объектларын (мәдәният тарихы ядкарьләрен) арендага бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2018 елның 26 маендагы 4-32 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 7 пункты (2025 елның 15 октябрендәге редакциядә), «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 10 пунктчасы нигезендә (29.11.2025 ред.), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы милкенә яисә муниципаль милеккә караган, торышы канәгатьләнерлек булмаган Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән файдаланылмый торган мәдәни мирас объектлары өчен ташламалы аренда түләвен билгеләү тәртибен һәм Татарстан Республикасы милкенә караган, торышы канәгатьләнерлек булмаган Россия Федерациясе халыкларының файдаланылмый торган мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) физик һәм юридик затларга арендага бирү тәртибен раслау турында» 2017 елның 9 ноябрендәге 852 номерлы карары, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Уставы белән Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы милкенә караган, торышы канәгатьләнерлек булмаган Россия Федерациясе халыкларының файдаланылмый торган мәдәни мирас объектларын (мәдәният тарихы ядкарьләрен) арендага бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2018 елның 26 маендагы 4-32 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Кушымтаның 7 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ рәсми рәвештә бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Буа муниципаль

районының мәгълүмати сайтында (http://buinsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль район башлыгы,
Совет рәисе Р.Р.Камартдинов